Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XVI-4**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 15 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы XIV-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен гражданнарга түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнарга милеккә бирү (тапшыру) Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Җир кодексының 32.1 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсенә таянып, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы XIV-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен гражданнарга түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнарга милеккә бирү (тапшыру) Тәртибенә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 12.07.2012 ел, №XVIII-13 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 4 пункттагы «гражданнарны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән исемлекләргә кертү турында (алга таба - исемлекләр)» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләре бирү (тапшыру) турында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 7 пунктта:

а) «муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «күчемсез милектнең дәүләт кадастры» сүзләрен «Күчемсез милек бердәм дәүләт реестры» сүзләренә алмаштырырга;

1.3) 8 пунктта «исемлекләрнең» сүзен «шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге), бакчачылык яки яшелчәчелек (алга таба - исемлекләр) алып бару өчен җир кишәрлеге алуга хокуклы гражданнар исемлеге,» сүзләренә алмаштырырга;

1.4) 12 пунктны «турыдан-туры вәкаләтле органга яки күп функцияле үзәк аша» сүзләре белән тулыландырырга;

1.5) 21 пунктта «гариза кергән көннән соң бер ай эчендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6) 23 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү көненә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган билгеләгән гражданнар заказлы хат белән тапшыру, телеграмма бирү турында хәбәрнамә яисә аларга хәбәр бирү юлы белән аны уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәр итә.»;

25 пунктта «әлеге маддә белән» сүзләрен «әлеге Тәртип белән » сүзләренә алмаштырырга;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, үзләре милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен тапшыруда кызыксынучы гражданнар, торак йортның урнашкан урыны буенча вәкаләтле органга аларга шушы җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итәләр. Гаризаның формасы вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

Гариза, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен турыдан-туры вәкаләтле органга яисә күпфункцияле үзәк аша файдаланып, язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.»;

1.9) 27 пунктның 1 - 4 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) тапшырыла торган җир кишәрлегендә урнашкан торак йортка күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) тапшырыла торган җир кишәрлегенә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3) торак йортка хокук билгели торган документ (әгәр әлеге торак йортка милек хокукы күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса);

4) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ (әгәр әлеге җир кишәрлегенә хокук күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса).»;

1.10)28 пунктта “алар биргән көннән” сүзләрен “кергән көннән” сүзләренә алмаштырырга;

1.11)29 пунктта «Нигезләмә» сүзен «Тәртип» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                        И.Г.Вәлиев